**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ТАТАР САРАЛАНЫ АВЫЛ**
**ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

422633,РТ,
Лаешрайоны,ТатарСараланыавылы,
Татарстан урамы, 17 нчейорт,
тел: 8 84378 4-77-49

**ГЛАВА ТАТАРСКО -САРАЛОВСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**ЛАИШЕВСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422633,РТ, Лаишевский район, село
ТатарскиеСаралы, ул. Татарстан, д.17
тел: : 8 84378 4-77-49

---

**2020елның 23 ноябре** **3номер**

# КАРАР

**2021 елга һәм 2022-2023еллар план чорына Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Татар Сараланы авыл җирлеге бюджеты проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында.**

Татар Сараланы авыл җирлегендә яшәүчеләрнең Татар Сараланы авыл җирлеге Советының карар чыгару проектлары буенча фикер алышуда катнашу хокукларын гамәлгә ашыру максатларында «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы һәм Татар Сараланы авыл җирлеге Уставының 19 статьясы нигезендә, карар бирәм**:**

1.Татар Сараланы авыл җирлегенең 2021 елга һәм 2022-2023 еллар план чорына бюджеты проекты буенча халык алдында тыңлауларны 2020 елның 07 декабренә 10.00 сәгатьтә Татар Сараланы мәдәният йорты бинасында билгеләргә..

2. Татар Сараланы авыл җирлегенең бюджет проекты буенча 2021 елга һәм 2022-2023 еллар план чорына тәкъдимнәр һәм искәрмәләрне язма рәвештә түбәндәге адрес буенча җибәрергә: Татарстан Республикасы, Лаеш районы, Татар Сараланы авылы, Татарстан урамы, 17 йорт яисә факс/тел. 4-77-49, email: Tsar.La@tatar.ru буенча 2020 елның 6 декабренә кадәр.

3. Җирлекнең башкарма комитетына 2021 елга һәм 2022-2023 елларның планлы чорына Татар Сараланы авыл җирлеге бюджеты проекты буенча гражданнарның гавами тыңлауларын үткәрүне, тәкъдимнәрен һәм искәрмәләрен кабул итүне һәм исәпкә алуны тәэмин итәргә.

4. Әлеге Татар Сараланы авыл җирлегенең 2021 елга һәм 2022-2023 елларның план чорына бюджеты проекты белән карарны ТР, Лаеш районы, Татар Сараланы авылы, Татарстан урамы, 17 йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмати стендта халыкка игълан итәргә һәм Интернет челтәрендәге Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Башлык-ТР Лаеш муниципаль районы**
**Татар Сараланы авыл җирлеге Советы рәисе** **И.Ф.Мөбәрәкшин**